**ГЛАВА БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Большой Битаман, ул.Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Битаман авылы, Мәскәү ур, 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22 ноябрь, 2021 ел** **№ 4**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман торак пункты гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 2 декабрендә 19.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Кече Битаман ав., Тау башы ур., 2В (мәдәният йортында).

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.2. Кече Битаман торак пунктында: «2022 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ

булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Кече Битаман торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлауга;
- вак таш сатып алу һәм Кече Битаман торак пункты эчендәге юлларны ремонтлауга юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы
вәкаләтләрен башкаручы Г.Н. Ибрагимова